| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА НОВОМАЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНА ЯҢА МАҖЫН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1** **08 октябрь 2022 ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге составына керүче Богодаровка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 08 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "2023 елда Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге Богодаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, I һәм 2 группа инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Чернобыль АЭСдә ликвидациядә катнашучылардан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Богодаровка торак пунктында юл эшчәнлеге, Күлле урамына ком-гравий катнашмасы сибү (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: сайлау хокукы булган җыенда катнашучылар исемлегенә 38 кеше кертелгән, 28 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенының 28 катнашучысы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлегенең  Богодаровка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2.  Әлеге сорау буенча карар кабул итергә: “2023 елда Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге Богодаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, I һәм 2 группа инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Чернобыль АЭСдә ликвидациядә катнашучылардан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-  Богодаровка торак пунктындагы Күлле урамына ком-гравий катнашмасы салу (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен Яңа Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итергә http://menselinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгы И.А.Колбин